КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 4 июнь г.Казань № 419

Саба муниципаль районында җир кишәрлеген бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, Саба муниципаль районының Измин авыл җирлеге башкарма комитетының Саба муниципаль районында урнашкан, «Измин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган 4,599 гектар мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлеген 16:35:070902:58 кадастр саны белән Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләрдә күрсәтелгән чикләрдә ритуаль эшчәнлек объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин